**СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Мульма, ул. Центральная, 46а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МҮЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы, Үзәк урамы, 46а

тел./факс 8(84365) 70-2-03, e-mail:Mulm.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**21 сентябрь 2020 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан Муниципаль берәмлек башлыгын сайлау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 9 пункты, 44 статьясындагы 2 өлеше нигезендә һәм хисап комиссиясенең 2020 елның 21 " сентябрендәге 2 номерлы беркетмәсе нигезендә, Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгын сайлау буенча яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга һәм 1 нче Мүлмә бермандатлы сайлау округы депутаты, Мүлмә авыл җирлеге башлыгы һәм Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы рәисе итеп Зиннәтүллина Эльвина Айдар кызын сайларга.
2. Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына керешү көне итеп, аны Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан сайланган көн дип санарга.
3. «Җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 өлеше һәм Мүлмә авыл җирлеге Уставының 43 статьясындагы 5 нче өлеше нигезендә Зиннәтүллина Эльвина Айдар кызын Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләп куерга.
4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Утырышта рәислек итүче
Мүлмә вәкиллекле органы
4 нче номерлы сайлау округы депутаты Р.В. Сәләхов